КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2023 ел, 21 декабрь

г.Казань

№ 1661

2023 елда локаль чистарту корылмаларын карап тотуга бәйле чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү максатларында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2023 елда локаль чистарту корылмаларын карап тотуга бәйле чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү максатларында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 21 декабрь, 1661 нче
карары белән расланды

2023 елда локаль чистарту корылмаларын карап тотуга бәйле чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү максатларында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән башка бюджетара трансфертлар бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртиптә 2023 елда локаль чистарту корылмаларын карап тотуга бәйле чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү максатларында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән башка бюджетара трансфертлар (алга таба шул ук эзлеклелектә – муниципаль район, башка бюджетара трансфертлар) бирү механизмы билгеләнә.

2. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

3. Башка бюджетара трансфертлар 2023 елда әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

4. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары:

локаль чистарту корылмаларын карап тотуга бәйле чыгым йөкләмәләре билгеләнә торган муниципаль хокукый акт булу;

муниципаль район бюджетында (муниципаль район бюджетының җыелма бюджет язмасында) локаль чистарту корылмаларын карап тоту вәкаләтләрен гамәлгә ашыру чыгымнарын түләүгә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан бирелергә планлаштырыла торган башка бюджетара трансфертларны үз эченә алган бюджет ассигнованиеләре булу;

әлеге Тәртипнең 11 пункты нигезендә Министрлык һәм муниципаль район арасында башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү.

5. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен муниципаль район Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

әлеге Тәртипнең кушымтасында бирелгән форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирүгә заявка (алга таба – заявка);

заявкага кул куйган затның вәкаләтләрен раслый торган документ;

локаль чистарту корылмаларын карап тотуга бәйле чыгым йөкләмәләре билгеләнә торган муниципаль хокукый актның расланган күчермәсе;

2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына муниципаль район бюджеты (муниципаль район бюджетының җыелма бюджет язмасы) турында муниципаль районның вәкиллекле органы карарыннан муниципаль район бюджетында (муниципаль район бюджетының җыелма бюджет язмасында) локаль чистарту корылмаларын тоту вәкаләтләрен гамәлгә ашыру чыгымнарын түләүгә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан бирелергә планлаштырыла торган башка бюджетара трансфертларны үз эченә алган бюджет ассигнованиеләре булуны раслый торган һәм вәкаләтле зат тарафыннан таныкланган өземтә.

6. Әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән, муниципаль районнан кергән документлар кергән көнендә теркәлә һәм Министрлык тарафыннан алар теркәлгән көннән алып биш эш көне эчендә карап тикшерелә. Документларны карап тикшерү йомгаклары буенча Министрлык җиде эш көне эчендә башка бюджетара трансфертлар бирү яисә бирүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карар турында муниципаль районга хәбәр итә.

7. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау яки тулы күләмдә тапшырмау яки әлеге Тәртипнең 6 пункты таләпләренә туры килми торган документларны тапшыру;

муниципаль район тарафыннан әлеге Тәртипнең 4 пунктында каралган башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары үтәлмәү.

Муниципаль район әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә алган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә документларны кабат тапшырырга хокуклы.

8. Әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка бюджетара трансфертлар бирүгә бүлеп бирелә торган бюджет ассигнованиеләре күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты акты белән билгеләнә.

9. Башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе – 2023 елда биш локаль чистарту корылмасын карап тоту.

10. Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү Министрлык тарафыннан башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәсенең килешүдә билгеләнгән һәм фактта ирешелгән мәгънәләрен чагыштыру нигезендә гамәлгә ашырыла.

11. Башка бюджетара трансфертлар башка бюджетара трансфертлар бирү турында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча Министрлык һәм муниципаль район арасында төзелә торган килешү нигезендә бирелә.

12. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме;

башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенең күрсәткече;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе һәм сроклары;

финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән башка бюджетара трансферт һәм йөкләмәләр бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисапларны тапшыру формасы һәм сроклары;

башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенең билгеләнгән күрсәткеченә ирешмәү нәтиҗәләре;

Министрлык белән дәүләт финанс контроле органнарының муниципаль район тарафыннан килешүдә каралган башка бюджетара трансфертлардан файдалану йөкләмәләренең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе.

13. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль районның финанс органына ачылган муниципаль район бюджетының бердәм счетына күчерелә.

14. Муниципаль район, 2024 елның бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнар турында хисап һәм башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап тапшыра.

15. Муниципаль район тапшырыла торган хисап белешмәләре дөрес булмаган һәм башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмаган өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

16. 2024 елның 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар 2024 елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемenә күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемenә түләтелергә тиеш.

Хисап финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларның калган өлешен әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга тотуга ихтыяҗ булган очракта, муниципаль район Министрлыкка 2024 елның беренче 15 эш көненнән дә соңга калмыйча шундый ихтыяҗны нигезләп мәгълүмат бирә.

Министрлык, муниципаль районнан әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны алган көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, агымдагы финанс елында хисап финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларның калган өлешен тотуга ихтыяҗ булу яисә булмау турында карар кабул итә.

Министрлык агымдагы финанс елында хисап финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларның калган өлешен тотуга ихтыяҗ булу турында карар кабул иткән очракта, Министрлык һәм муниципаль район арасында мондый карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган форма буенча килешүгә өстәмә килешү төзелә.

17. Муниципаль район тарафыннан башка бюджетара трансфертлар максатчан файдаланылмаган һәм (яки) аларны бирү шартлары бозылган, шул исәптән муниципаль берәмлек тарафыннан акча Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмаган очракта, муниципаль районга карата Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган бюджет мәҗбүр итү чаралары кулланыла.

18. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары әлеге Тәртиптә һәм килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

19. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын контрольдә тоту Министрлык тарафыннан законнар нигезендә башкарыла.

2023 елда локаль чистарту корылмаларын карап тотуга бәйле чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү максатларында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә кушымта

Форма

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры

_____________________________________________

(муниципаль район җитәкчесе
(аның вазыйфаларын башкаручы зат) тулысынча)

_____________________________________ тан (дан)

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)

2023 елда локаль чистарту корылмаларын карап тотуга бәйле чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү максатларында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән башка бюджетара трансфертлар бирүгә
заявка

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елда локаль чистарту корылмаларын карап тотуга бәйле чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү максатларында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 21 декабрь, 1661 нче карары белән расланган 2023 елда локаль чистарту корылмаларын карап тотуга бәйле чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү максатларында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе нигезендә

_________________________________________________________________________на
(муниципаль район исеме)
___________________________________________________________________________
(чараның исеме, башка бюджетара трансферт бирү максатлары)
_______________________________________________________________________ өчен
__________________(_________________________________) сум ___ тиен күләмендә
(сумма цифрлар белән) (сумманы тутырып язу)
башка бюджетара трансферт бирүегезне сорыйм.

Бу заявкада бирелгән белешмәнең дөреслеген һәм тулылыгын раслыйм.

Дөрес булмаган белешмә һәм документлар биргән өчен җаваплылык турында кисәтелдем.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча бюджетара башка трансфертлар алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылган, башка бюджетара трансферт биргәндә билгеләнгән шартлар, максатлар һәм тәртип, башка бюджетара трансферттан файдалану бозылган очракта, бирелгән башка бюджетара трансфертны Татарстан Республикасы бюджеты керемнә кире кайтарырга тиеш турында беләм.

Җитәкче
(аның вазыйфасын башкаручы зат) ______________/____________________________/
(имза) (Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

М.У.

Дата: 20__ елның «__» __________

________________________________